Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР №9**

Зур Мәшләк авылы 2024 елның 11 нче июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге депутаты М.Г. Заһидуллинның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясы, Балык Бистәсе муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының, Заһидуллин Марат Габделбәр улының 10.06.2024 елгы үз теләге белән вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы гаризасы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге депутаты Заһидуллин Марат Габделбәр улының үз теләге белән отставкага китүенә бәйле рәвештә 2024 елның 11 июненнән 1 нче бермандатлы сайлау округы буенча сайланган вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.
2. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13а йорты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24а йорты, Бикчурай авылы, М.Горький урамы һәм Балык Бистәсенең рәсми сайтында- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары В.И. Вафина